

Вл. Маяковский

УТ-АТ

ТАТКНИГОИЗДАТ · 1957

В. МАЯКОВСКИЙ

УТ-АТ



Ә. ИСХАК тәрҗемәсе

ТАТКНИГОИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ РЕДАКЦИЯСЕ
КАЗАН 1957

* * *

Редакторы
К. Г. КОТДУСОВА

Тышлык художнигы
Л. П. АНИСИМОВ
Е. М. СИДОРКИН
рәсемнәре

* * *

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

В. МАЯКОВСКИЙ

КОНЬ-ОГОНЬ

(на татарском языке)

Художество редакторы *Э. Е. Дьячкова*
Техник редакторы *И. Х. Зәйнуллин*
Корректоры *М. М. Мирсалихова*

Наборга бирелде 31|VII-1957 ел. Басарга кул куелды 29|X-1957 ел. Кәгазь форматы 70 × 92$^1/_{16}$.
Учет-изд. табак 0,81. Басма табак 0,75 (0,88). Табакта 44000 хәреф.
Заказ № 0301. Тираж 14 000. Бәясе 35 тиен.

ТАССР Культура министрлыгының Татполиграф типографиясе. Казан, Миславский ур., йорт № 9.



Кибеткә әйдәп
этисен,
әйткәндер улы
йөз кат:
— Кавалерист булып үсәм.
Китер,
эти,
миңа ат!
Нигә бик озак уйларга?
Уенчык —
кибет тулы.
Дүрт аяклыны алырга
китте
ата һәм улы.
Кибеттә
җавап бирделәр:
— Бүгенгә —
ат юк, — диделәр. —
Мастер кирәк моның өчен,
Ул ясый
атның төрлесен...

Ә мастер
　　　　әйтте аларга:
— Катыргы кирәк табарга.
Гәүдәне
　　　　андый атларга
мөмкин
　　　　тик шуннан ясарга.
Бар да
　　　　киттеләр шунда
Кәгазь фабрикасына.



Эшче алардан сорады:
— Сезгә
нирдиерәген?
Һәм, күп тә үтми, чыгарды
өч табак
иң-иң шәбен.
— Менә келәй дә
алыгыз.
Нык булыр,
келәй салыгыз!
Атта йөргән —
үзе белә:
йөрми ул
көпчәксез генә.






Бар да столярга бара.
Ул шатланып каршы ала.
Һәм ясап бирә
шунда ук
бик шәп итеп
дүрт көпчәк.
Көпчәкләр булды,
ялы юк,
юк койрыгы, —
кыл кирәк.
Ә кылны каян табарга?
— Кыл
щетка ясаучыларда!
Каршы килми,
щеткачы да
кыл бирде аларга шунда, —
атка
ял куяр өчен
һәм койрык тагар өчен.
Карыйлар —
кадаклары юк.
Кадаксыз булмый шулай ук!



Җыелып
бар да бергә
киттеләр тимерчегә.
Тимерче дә
бик шатланып,
кадаклар бирде чыгарып:
— Рәхим итегез, кунаклар!
Мәгез,
бик яхшы кадаклар!
Эшкә тотынганчы алар, —
нәрсә җитми? —
барладылар.





Бар да килде бер сүзгә:
— Болар гына аз безгә.
Болай
ат начар булачак,
күңелсез,
ямьсез чыгачак.
Буярга
һәм күз ясарга,
кирәк
художник табарга.
Һәм кавалерист йөгерә,
художник янына керә:
— Иптәш,
безгә
сез бер ат
бирмәссез микән буяп?
— Була ул! —
һәм чыга үзе,
буяу алып
төрле төсле.

Ясый башладылар атны.
Эш кызып китте шул чакны.
Калган вакытны алар
бушка уздырмадылар.
Табып атны ясау өчен
Материалның иң яхшысын,
Бар да бергә керештеләр.
Ак катыргыны кистеләр.
Күп итеп keләй салдылар.
Тояклар да ясадылар.
Щеткачы койрык, ял такты.
Тимерче кадаклар какты.
Столяры да бигрәк җитез —
көпчәкләр шомарды бик тиз.





Художник буяды тәнен
һәм ясап куйды күзләрен.
Килеп чыкты шундый ат, —
уттан да кызуырак!
Алга да, артка да бара,
сикерә һәм юрта ала.
Зәп-зәңгәр күз генәсе,
алма-чуар гәүдәсе.
Иярле һәм йөгәнле,
бәйләп куйган өзәңге.
Атлан да утыр гына
һәм булыш Буденныйга.



Бэясе 35 тиен

